ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№368 от «21» 09 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш районы
Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый
торак комиссиясе турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Дәүләт торак фондының 2023 елның 25 июлендәге 8477 номерлы мөрәҗәгатен карап, "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" федераль программасын, "Социаль ипотека" республика программасын гамәлгә ашыру һәм гражданнарга торак шартларын яхшыртуда ярдәм итү, авыл җирлегендә торак төзү һәм торак сатып алу өчен социаль түләүләр алучыларның җыелма исемлекләренә керткәндә җәмәгатьчелек контролен һәм коррупцион хокук бозуларны профилактикалауда ярдәм итү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 06 апрелендәге 146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш районы башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясе турындагы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 4.6 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Х.Әгъләмов

0000011974